КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 7 сентябрь г.Казань № 800

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 30 декабрь, 1097 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1096 нчы; 2015 ел,

6 ноябрь, 325 нче; 2015 ел, 12 ноябрь, 847 нче; 2016 ел, 1 март, 127 нче; 2016 ел, 4 июнь, 372 нче; 2017 ел, 12 май, 276 нчы; 2017 ел, 29 июль, 529 нчы; 2017 ел, 28 август, 609 нчы; 2018 ел, 18 июнь, 493 нче; 2018 ел, 12 сентябрь, 773 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1218 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 нче пунктта:

17 нче таблицаның исемендә «социаль хезмәт күрсәтүнең стационар һәм ярымстационар формалары» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасы» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $17^1$ нче таблица өстәргә:

«$17^1$ нче таблица

Социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасы булган мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларны йомшак инвентарь белән тәэмин итү нормативлары

| Т/с | Инвентарь исеме | Үлчәү берәмлеге | 1 елга 1 урынга уртача норматив | Шул исәптән | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | кызларга норматив | малайларга норматив |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Простыня | данә | 1,50 | 1,50 | 1,50 |
| 2. | Юрган тышы | данә | 1,00 | 1,00 | 1,00 |
| 3. | Мендәрнең аскы тышы | данә | 0,25 | 0,25 | 0,25 |
| 4. | Мендәрнең өске тышы | данә | 1,50 | 1,50 | 1,50 |
| 5. | Сөлге | данә | 2,00 | 2,00 | 2,00 |
| 6. | Байкадан тегелгән юрган | данә | 0,20 | 0,20 | 0,20 |
| 7. | Матрац | данә | 0,17 | 0,17 | 0,17 |
| 8. | Япма | данә | 0,20 | 0,20 | 0,20 |
| 9. | Мамык-каурый мендәр | данә | 0,25 | 0,25 | 0,25 |
| 10. | Карават янындагы кечкенә келәм | данә | 0,20 | 0,20 | 0,20»; |

2.5.3 нче пунктта:

бишенче, җиденче һәм сигезенче абзацларда «34 нче таблица» сүзләрен «34 нче һәм $34^1$ нче таблицалар» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $34^1$ нче таблица өстәргә:

«34[1] нче таблица

Социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасы булган
мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә
социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларны
санитария-гигиена билгеләнешендәге товарлар белән тәэмин итү нормасы

| Т/с | Санитария-гигиена билгеләнешендәге товарлар исеме | Үлчәү берәмлеге | Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә 1 көнгә койка-урынга норма |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Бәдрәф сабыны | данә | 0,0476 |
| 2. | Бәдрәф кәгазе | рулон | 0,0178 |
| 3. | Балалар сабыны | данә | 0,0055»; |

3.9 нчы пунктның тугызынчы абзацында «социаль-көнкүреш, социаль-педагогик, социаль-хокукый хезмәтләр күрсәтүче персонал өчен – 1,25; социаль-медицина хезмәтләре күрсәтүче персонал өчен – 1,125» сүзләрен «социаль-көнкүреш, социаль-педагогик, социаль-хокукый хезмәтләр күрсәтүче персонал өчен – 1,125; социаль-медицина хезмәтләре күрсәтүче персонал өчен – 1,25» сүзләренә алыштырырга;

5.3 нче пунктның 53 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«53 нче таблица

| Оешма төре, социаль хезмәт күрсәтү формасы | Халык саны, мең кеше | Социаль хезмәтләр күрсәтүче персонал хезмәтләренең стандарт (база) кыйммәтенә һәм хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт өчен түләү фондына төзәтү коэффициентлары | |
|---|---|---|---|
| | | шәһәр җирлеге | авыл җирлеге |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасы булган һәм гаиләгә һәм балаларга ярдәм күрсәтү үзәкләрендә һәм комплексы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга ярдәм күрсәтү бүлекчәләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярым стационар формасы булган оешмалар | 16 меңгә кадәр | 1,085 | 1,085 |
| | 16 меңнән 70 меңгә кадәр | 1,000 | 1,000 |
| | 71 меңнән 100 меңгә кадәр | 0,900 | 1,000 |
| | 101 меңнән 600 меңгә кадәр | 0,800 | 1,000 |
| | 601 меңнән һәм аннан югарырак | 0,750 | 1,000». |

2. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин